ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2021 г.Лениногорск № 377

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 28 декабрендәге 1504 номерлы «Лениногорск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәләрен бирү Тәртибен раслау турында» карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәләрен бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен өстәмә түләүне билгеләү турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм педагогик кадрларны беркетү максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 28 декабрендәге 1504 номерлы «Лениногорск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәләрен бирү Тәртибен раслау турында» карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь

белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәләрен бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. яшь белгеч - 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданы (Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш), төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча укуны тәмамлаган, алынган квалификация нигезендә беренче тапкыр эшкә урнашкан».

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы В.С. Санатуллинга йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72